БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«_25__» ____12__ 2019 г. № _389___

«Балтач муниципаль районы территориясендә муниципаль торак фондыннан файдалануга һәм аны саклауга, әлеге фондның торак урыннарының билгеләнгән санитария һәм техник кагыйдәләргә һәм нормаларга, законнарның башка таләпләренә туры килүенә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру турында»гы административ регламентны раслау хакында» Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2019 елның 24 маендагы 211 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Торак кодексының 20 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль закон, «Гражданнарның торак хокукларын яклауны тәэмин итү турында» 2011 елның 10 октябрендәге 72-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль контрольне гамәлгә ашыру буенча муниципаль вазыйфаларны үтәүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 23 апрелендәге 275 номерлы карары, Балтач муниципаль районы Уставы нигезендә Балтач муниципаль районы башкарма комитеты карар бирә:

1. «Балтач муниципаль районы территориясендә муниципаль торак фондыннан файдалануга һәм аны саклауга, әлеге фондның торак урыннарының билгеләнгән санитария һәм техник кагыйдәләргә һәм нормаларга, законнарның башка таләпләренә туры килүенә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру турында»гы административ регламентны раслау хакында» Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2019 елның 24 маендагы 211 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 бүлектәге 2.4.1 пунктның 3 абзацында «өч ел» сүзләрен «бер ел» сүзләренә алмаштырырга»;

1.2. 8 бүлектәге 8.4 пунктының 3 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Җирле үзидарә органы яисә вазыйфаи зат, цензурасыз яисә кимсетүле сүзләр, вазыйфаи затның, шулай ук аның гаилә әгъзаларының тормышына, сәламәтлегенә һәм мөлкәтенә янаулар булган язма мөрәҗәгать алганда, мөрәҗәгатьне анда куелган сорауларның асылы буенча җавапсыз калдырырга һәм мөрәҗәгать җибәргән гражданга хокуктан явызларча файдаланырга ярамавы турында хәбәр итәргә хокуклы.»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Интернет мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрдә Балтач муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач районы башкарма комитетының Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык бүлеге башлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы Балтач район башкарма
комитеты җитәкчесе А. Ф. Хәйретдинов